ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл җирлеге

422742. Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авылы.
Киров урамы. 1А
тел. 3-53-97, факс 3-53-40

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Атнинский муниципальный район
Кулле-Киминское сельское поселение

422742. Атнинский муниципальный район
с.Кулле-Кими,
ул. Кирова. 1А
тел. 3-53-97, факс 3-53-40

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«10» ноябрь 2025 г. № 5

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күлле-Киме авыл җирлеге Ары торак пунктында
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

2025 елның 20 мартындагы « Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ номерлы Федераль законының 45, 69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2025 елнын 25 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенә керүче Ары торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.1.Билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Ары торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Башкарма комитеты;

-гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 2025 елның 25 ноябре 15:00 сәгатькә;

-үткәрү урыны – Ары авылы, К.Маркса урамы,2А йорты;

1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 19 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Күлле-Киме авылы, Киров урамы, 1А йорты;

- сайлау хокукына ия булган Ары торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;

-гражданнар җыены турында Ары торак пункты халкына мәгълүмат стендлары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итергә;

1.3. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2026 елда Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Ары торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) торак пункт территорияләрен төзекләндерү (үлән чабу, агачларны кисү, иске биналарны сүтү, эш һәм хезмәтләр өчен түләү)

2) Урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, аларга мәйданчыкларны, электр элемтәләрен тәэмин итүгә һәм электр энергиясен тапшыруга билгеләнгән бүлү пунктларын һәм башка җиһазларны ремонтлау; (урам яктырткычларын тәэмин итү һәм яктырткычлар сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү)

3) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (урамнарны кардан чистарту, Ары авылы юлын ремонтлау, вак таш сатып алу һәм җәю, эш һәм хезмәтләр өчен түләү)»

"РИЗА" "КАРШЫ"

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Күлле-Киме авылы, Киров урамы 1А йорты адресы буенча урнашкан стендка урнаштырырга.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы: Гиниятов И.С.